Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге составына керүче Олы Әшнәк авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАРЫ**

30 октябрь 2019 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Әшнәк авыл җирлеге составына керүче Олы Әшнәк авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Олы Әшнәк авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

- Олы Әшнәк авылының Мәктәп урамында, Кече Әшнәк авылының Совет урамында юлны ремонтлауга;
- Олы Әшнәк һәм Кече Әшнәк авылларында контейнер мәйданчыклары ясауга;
- кышын Олы Әшнәк һәм Кече Әшнәк авылларында урамнарны карап торуга (кардан чистартуга);
- урам утларына электр энергиясен саклаучы лампалар сатып алуга;
- ветеринария чараларын уздыру өчен Кече Әшнәк авылында раскол (станок) ясау.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Әшнәк авылы, Г.Тукай урамы, 28а йорты;Кече Әшнәк авылы, Кызыл Армия урамы, 32а йорты һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Хөснетдинова Р.Ә.

Олы Әшнәк авыл җирлеге башлыгы Хөснетдинова Р.Ә.